**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 22 октябрендәге 4459 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 25 октябрендәге 3630 номерлы «Өстәмә гомуми белем бирү программалары һәм спорт әзерлеге программалары буенча укытуга язылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

2024 елның 8 июлендәге 172-ФЗ номерлы «“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 25 октябрендәге 3630 номерлы карары белән расланган Өстәмә гомуми белем бирү программалары һәм спорт әзерлеге программалары буенча укытуга язылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент), Регламентның 3.6.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.6.3.4 пунктчасын өстәп, үзгәреш кертергә:

«3.6.3.4. Балигъ булмаган затның законлы вәкиле булып торган гариза бирүче балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда, балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукы балигъ булмаган затның гариза бирүче булып тормаган законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаган затның гариза бирүче законлы вәкиле, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә, балигъ булмаган затка карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле балигъ булмаган затның башка законлы вәкиленең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), шәхесен таныклый торган документ турында белешмәләрне күрсәтә.

Балигъ булмаган затның гариза бирүче булып тормаган законлы вәкиленә балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы

документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен тапшыру әлеге Регламентның 3.6 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта гариза бирүче язма рәвештә балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең соратылган нәтиҗәләрен шәхсән алу теләген белдергән очракта, балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре балигъ булмаган затның башка законлы вәкиленә бирелә алмый».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**